РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-42-05, факс: (85593) 2-80-13

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-42-05, факс: (85593) 2-80-13

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 28 » 12 2024 ел №1244

2025 елга күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йорттагы торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен үзгәртүнең чик индексы турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 158 статьясындагы 4 өлеше нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, Россия Төзелеш Министрлыгының 06.04.2018 ел, № 213/пр "Күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында Карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү буенча методик киңәшләрне раслау турында, торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында, шулай ук мондый түләү күләмен үзгәртүнең чик индексларын билгеләү тәртибен билгеләү турында»гы боерыгы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы законы нигезендә, "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башкарма комитеты к а р а р и т т е:

1. 2025 елга күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында Карар кабул итмәгән күпфатирлы йорттагы торак урыннарның милекчеләре өчен торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен үзгәртүнең чик индексын 7,1% күләмендә расларга.
2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының «2024 елга күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йорттагы торак урыннарның милекчеләре өчен торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен үзгәртүнең чик индексы турында»гы 17.01.2024 елның 38 санлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru; Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм

коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан бирелгән 17.12.2013 ел, №ФС77-60244 ЭЛ массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык) буенча бастырырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм Порталы составында «Рәсми Татарстан» мәгълүматтелекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина

Габдрахманова Г.Г.
2-42-06